РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«8» июль 2020 ел. г. Альметьевск № 77

Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2019 елның 18 январендәге 06 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәхси эшмәкәрләрнең гаризаларын карап,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы 2019 елның 18 январендәге 06 номерлы карарына (Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 7 февралендәге 16 номерлы, 2019 елның 16 апрелендәге 40 номерлы, 2019 елның 11 июнендәге 58 номерлы, 2019 елның 5 июлендәге 67 номерлы, 2020 елның 17 январендәге 02 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы 44 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлмәт шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасының 1 пунктында 39 нчы юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Реестр номеры № | Стационар булмаган сәүдә объектларының атамасы һәм урнашу урыны (Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре) | Сатыла торган товарның ассортименты | Стационар булмаган сәүдә объектларының тибы (павильоннар, киоск, автомагазин, автолавка, тонар, лоток, контейнер, һ.б.) | Мәйданы, кв.м | Сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларыннан файдалану турында мәгълүмат | Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 39 | Ленин ур., 128 йорт, Спортмастер янындагы территория | пиротехника | павильон | 50 гә кадәр | сәүдә | 5 елга кадәр |

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Зак. № 301

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Вәлиев